**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422731, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Мульма, ул. Центральная, 46а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мүлмә авылы, Үзәк ур., 46а

Тел./факс: +7(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**28 февраль 2023 ел** **№3**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Башкарма комитетының "Мүлмә авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яки әйберләр яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында"02.04.2021 ел, №12 карары үз көчен югалтуын тану хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында " 2022 елның 24 июлендәге 1885 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, прокурор тәкъдиме белән бәйле рәвештә, Биектау районы хокук чыгару инициативасы тәртибендә, Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Мүлмә авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яки әйберләр яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында" Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге башкарма комитеты кабул иткән 02.04.2021 ел 12 нче номерлы карарның үз көчен югалтуын таныйрга (09.06.2021 ел, №19 карар редакциясендә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырып игълан итәргә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру гамәлләре турында хисаплар http://pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карар 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Мүлмә авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Л.Р. Зиннәтуллин